Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР№XXXII-6**

Балык Бистәсе штп. 24 июль 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 28 декабрендәге “Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районында 2018 елга күп фатирлы йортта торак бинаны тоту өчен бинадан файдалану хакы (наем өчен түләү) күләме турында” гы XXV-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга тәңгәлләштерү максатындаРоссия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 маддәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы”Күп фатирлы йортта уртак милекне тоту кагыйдәләрен һәм хезмәт күрсәтү һәм идарә итү, күп фатирлы йортта уртак милекне тоту һәм ремонтлау буенча тиешле сыйфатсыз һәм (яки) билгеләнгән дәвамлылыктан артып киткән туктап торулар белән эшләр башкару очрагында торак бинаны тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме үзгәрү кагыйдәләрен раслау турында”гы 491 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге “ Дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак биналарын социаль наем килешүләре һәм наем килешүләре буенча яллаучылар өчен торак бинадан файдаланганга түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында”гы 668/пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 28 декабрендәге “2018 елга Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районында торак бинадан файдалану (наем өчен түләүләр), күп фатирлы йортны тоту өчен түләүләр күләме турында”гы XXV-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 пункттагы “кушымтага ярашлы рәвештә” дигән сүзләрне “1 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә” дигән сүзләргә алмаштырырга;

1.2)түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга:

“1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль торак фондыныңторак биналарын социаль наем килешүләре һәм наем килешүләре буенча яллаучылар өченторак бинадан файдаланганга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне 2 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә расларга;

1.3) кушымтада җиденче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Торак бинадан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) | Торак бинаның гомуми мәйданы айга кв.м ларда | 5,00 | 5,87» |

1.4)карарга кушымтага ярашлы рәвештә 2 номерлы кушымта белән тулыландырырга.

2.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 28 декабрендәге
XXVI-2 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 24 июлендәге
XXXII-6 номерлы карары
редакциясендә)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
муниципаль торак фондыныңторак биналарын социаль наем килешүләре һәм
наем килешүләре буенча яллаучылар өченторак бинадан файдаланганга түләү
(наем өчен түләү) күләмен исәпләү тәртибе турында
Нигезләмә

1. Вакытлыча файдалануга алган торак (наем) өчен түләү наемның база ставкасыннан чыгып, торак бинаның сыйфатын һәм төзекләндерелгәнлеген, йортның урнашу урынын, шулай ук хакына туры килү коэффициентын характерлаучы коэффициент кыйммәтләрен исәпкә алып билгеләнә.

Торак бина наемы өчен исәпләүләрнең гомуми суммасы 1 формула буенча билгеләнә:

1 формула

$П_{нj} = Н_б * К_j * К_с * П_j$,

Формулада: $П_{нj}$ – дәүләт яки муниципаль торак фондының социаль наем килешүе яки торак бинаның наем килешүе буенча бирелгән j-нчы торак бина наймы өчен түләү күләме;

$Н_б$ – торак бинаның наемы өчен түләүнең база күләме;

$К_j$ – торак бинаның сыйфатын һәм төзекләндерелгәнлеген, йортның урнашу урынын характерлаучы коэффициент;

$К_с$ – хакына туры килү коэффициенты;

$П_j$ - дәүләт яки муниципаль торак фондының социаль наем килешүе яки торак бинаның наем килешүе буенча бирелгән j-нчы торак бинаның гомуми мәйданы (кв.м. ларда).

Балык Бистәсе муниципаль районының барлык категория кешеләре өчен хакына туры килү коэффициенты зурлыгы 0,1 күләмендә билгеләнә.

2. Торак бинадан файдаланган өчен түләүнең база күләме 2 формула буенча билгеләнә: 2 формула

$Н_Б= СР_с*0,001$

формулада:

$Н_Б$ – торак бина наемы өчен түләүнең база күләме;

$СР_с$ – дәүләт яки муниципаль торак фондының социаль наем килешүе яки торак бинаның наем килешүе буенча бирелгән торак бина урнашкан Татарстан Республикасы икенчел торак базарында фатирларның гомуми мәйданы 1 кв.м ының уртача бәясе.

База күләме Татарстан Республикасы буенча Дәүләт статистика федераль хезмәтенең территориаль органы мәгълүматлары буенча икенчел торак базарындагы 1 кв.м.ның уртача бәясеннән чыгып билгеләнде (2018 елның 1 кварталына күләм 58 796,6 сумны тәшкил итте).

2018 елга торак бинадан файдаланган өчен түләүнең база күләме ($Н_Б$) кв.м.га 58,79 сум тәшкил итте.

Шулай итеп,хакына туры килү  коэффициенты белән бергә наем өчен түләү күләме кв.м. га 5, 87 сумга тигез.

3. Торак бина наемы өчен түләү күләметорак бинаның сыйфатын һәм төзекләндерелгәнлеген, йортның урнашу урынын характерлаучы коэффициентларны файдаланып билгеләнә.

$К_1$коэффициенты түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_1 = \frac{К_м + К_{св} + К_{пл}}{3},$$

$К_1$, $К_2$ , $К_3$, $К_м$, $К_{св}$, $К_{пл}$, – таблицада күрсәтелгәнкоэффициентлар.

| Коэффициент | Куллану сыйфатлары | Коэффициент кыйммәте |
|---|---|---|
| Торак бинаның сыйфатын характерлаучы коэффициентлар ($К_1$.) | | |
| $К_м$ | Диварларның материалы | |
| | кирпеч, таш | 1,2 |
| | блоклы, эре панельле | 1,0 |
| | катнаш яки агач | 0,5 |
| $К_{св}$ | Йортларның файдалануга тапшырылу срогы: | |
| | 1996 елдан | 1,2 |
| | 1975 елдан 1996 елга кадәр | 1,0 |
| | 1960 елдан 1975 елга кадәр | 0,6 |
| | 1960 елга кадәр | 0,4 |
| $К_{пл.}$ | Торак бинаның планировкасы | |
| | яхшыртылган | 1,2 |
| | стандарт | 1,0 |
| | Стандарт булмаган (ш.и.. коммуналь, тулай торак һәм гостиница тибында) | 0,5 |
| Торак бинаның төзекләндерелгәнлеген характерлаучы коэффициент($К_2$.) | | |
| | Торак бинаның төзекләндерелүе | |
| | Торак бина барлык уңайлыкларыбелән (суүткәргеч, канализация, кайнар су белән тәэмин ителү( үзәктән яки | 1,2 |

| | | |
|---|---|---|
| | урындагы су җылыткычтан), җылыту, газ) | |
| | Торак бина өлешчә төзекләндерелгән (уңайлыкларның берәрсенең булмавы) | 1,0 |
| | Тузган һәм авария хәлендәгегә керә | 0,8 |
| Йортның урнашу урынын характерлаучы коэффициент ($К_{3.}$) | | |
| | Урнашу урыны: | 1,0 |

Торак бина өчен$К_к$ның интегралькыйммәтеаерым параметрлар буенча күрсәткечләрнең арифметик уртасы буларак түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_к = \frac{К_1 + К_2 + К_3}{3},$$